# Хәбәр

Җөмләнең **ия** турында хәбәр итә һәм аның белән бәйләнеп килә торган баш кисәге.

Фигыль хәбәр

Исем хәбәр

# Сораулары

Нишлә?

Күпме?

Нинди?

Һ.б.

1. Бер тавыш килде колакка, яңгырады бер заман…(Г. Тукай.)

2. Карлыгачлар искиткеч тату, бердәм халык. (Г.Хәсәнов.)

3. Бер-булды, ике- булды, урта бармак-өченчесе. (М.Галиев.)

# Фигыль хәбәр

# Гади фигыль хәбәр

1. Таллар,тынып,уйчанланып,башларын суга игәннәр.(А.Шамов.)

2. Иртәгә шушы вакытта Әхмәт абзый тагын су алырга төшәчәк.( М.Мәһдиев.)

3. Гөр, шау-шу әкренләп басылды.( А. Шамов.)

# Тезмә фигыль хәбәр

Фразеологизмнар

Таркалмый торган сүзтезмәләр

1. Ул үз-үзен кулга алырга өлгерде. ( Х.Сарьян.)

2. Кылт итеп искә төшәдер намнары, дәүләтләре…

( Г.Тукай.)

3. Юлыбыз һаман дәвам итә.

( Г.Тукай.)

# Кушма фигыль хәбәр

Фигыль + Ит, бул, исә, иде ,ал, бел, икән, яз, җибәр, башла, тотын,кереш һ. б.

1. Кырлар өстендә, күзне камаштырып, язгы карның көмеш бизәге балкып тора. ( Г.Бәширов.)

2. Анның тавышында хәзер дулкынлану һәм нәрсәгәдер соклану, горурлану сизелә иде. (Г.Бәширов.)

3. Болын да чалгычыны көтә башлады. (Г.Хәсәнов.)

# Исем хәбәр

Гади

Кушма

Тезмә

Гади исем хәбәр.

1.Безнекеләр-сабыр .( Зөлфәт.)

2.Чират буенча мин-алтынчы.(Г.Бәширов.)

3. Амбар төбендә икмәк бар, картлар сүзендә хикмәт бар.(Мәкаль)

# Тезмә исем хәбәр

1.Су анасы мин… ( Г.Тукай.)

2. Ә хәле аның- җилкә кашырлык .( Х. Сәрьян)

3. Зөлфияләрнең өйләре- калай түбәле. Г.Лотфи.)

Кушма исем хәбәр

Фигыльдән кала сүз төркемнәре

+

иде, икән, бул, тор, түгел, әле, бугай, ахры,соң

1. Зөһрә –минем бик яшерен йөрәк серем иде.(Ә.Еники.)

2. Төз түгел куллар, аяклар да-ботак-тармак кеби.( Г.Тукай)

3. Һәр таш монда миңа таныш сыман. (Зөлфәт)

# Хәбәрне тикшерү тәртибе

1. Җөмләнең хәбәре билгеләнә.
2. Хәбәрнең нинди булуы әйтелә: гади фигыль хәбәр, гади исем хәбәр, кушма фигыль хәбәр, кушма исем хәбәр.
3. Хәбәрнең ничек белдерелүе әйтелә:
а) гади фигыль хәбәр- кайсы фигыль төркемчәсе;
ә) гади исем хәбәр- нинди сүз төркеме;
б) кушма фигыль хәбәр-фигыль төркемчәсе һәм ярдәмче фигыль; яки фигыль төркемчәсеһәм ярдәмче фигыль функциясендә килгән мөстәкыйль фигыль;
в)кушма исем фигыль-нинди сүз төркеме һәм ярдәмче фигыль.
4. Хәбәр ия белән яраклашкан булса, нәрсәдә яраклашкан икәнлеге билгеләнә.

# Кабатлау

1. Хәбәрнең җөмләдәге функциясен аңлатыгыз.
2. Хәбәр нинди сүз төркемнәре белән белдерелә?
3. Гади фигыль хәбәр кайсы очракта ия белән зат-санда яраша?
4. Кушма хәбәрләрдә хәбәрнең төп мәгънәсе кайсы өлештә бирелә?
5. Ярдәмче фигыльләр нәрсәне белдерә?

## Җөмләләргә бирелгән хәбәрләрне туры китереп языгыз.

1. Аш кадерен ач … ,тун кадерен ялангач … . 2. Батыр яуда … , телчән дауда … .
3. Бүредән курыккан урманга … .
4. Мәдинәнең өе мәктәптән шактый … .
5. Әңгәмә аны бик … . 6. Безнең песи- … .
7. Бер карасаң, дөнья- тоташ …, бер карасаң- гади … .

Хәбәрләр: уен гына, ерак, беленер, кызыксындырды, белер, җиденчесе, сугыш, бармас.